КОНСТИТУЦИОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛ ИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СОВЕТЫ

ул. Пушкина, д. 66/33, г. Казань, 420060
тел. 8(843)598-32-98, E-Mail: konsovrt@tatar.ru

Пушкина ур., 66/33 йорт, Казан шәһәре, 420060
тел. 8(843)598-32-98, E-Mail: konsovrt@tatar.ru

23 октябрь, 2025 ел № 5

**Гражданка Д.Г.Йосыпова мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә, «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 2023 елның 21 июлендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең конституциячеллеген тикшерү хакында**

# НӘТИҖӘ

Татарстан Республикасы Конституция Советы, Рәисе И.И.Гыйлэҗев, әгъзалары Р.Ф.Гафаров, Э.М.Мостафина катнашында, «Татарстан Республикасы Конституция советы турында» 2023 елның 13 июнендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 2 өлешенә, 11 статьясына таянып, «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 2023 елның 21 июлендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешенең Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 статьясындагы икенче өлешенә, 50 статьясындагы беренче һәм өченче өлешләренә туры килүен тикшерде.

Гражданка Д.Г. Йосыпованың мөрәҗәгате тикшерүгә сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгатьтә билгеләнгән норматив-хокукый акт нигезләмәсенең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек тикшерү өчен нигезгә әйләнде.

Татарстан Республикасы Конституция советы, Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзасы - докладчы Р. Ф. Гафаров мәгълүматларын, утырышта катнашучыларның – гражданка Д. Г. Йосыпова, карауга кертелгән норматив-хокукый актны чыгарган орган вәкиле – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең граждан законнары бүлеге баш киңәшчесе Е.Н. Ситдыйкова аңлатмаларын, утырышка чакырылганнарның: Татарстан Республикасы Рәисе вәкиле – Татарстан Республикасы Рәисе Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектлары буенча бүлеге баш киңәшчесе Л. К. Вәлиуллина, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Дәүләт автоинспекциясе идарәсе вәкиле – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Дәүләт автоинспекциясе идарәсе техник күзәтчелек бүлеге башлыгы урынбасары В.В.Кондратьев, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вәкиле

– Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре буенча бүлеге әйдәп баручы консультанты А.Ф. Хөсәенов, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил вәкиле – Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлегенең баш киңәшчесе Ю.В. Гаврилова чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны тикшергәннән соң,

БИЛГЕЛӘДЕ:

1. Татарстан Республикасы Конституция советына гражданка Д.Г. Йосыпова «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 2023 елның 21 июлендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук – 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) 6 статьясындагы 1 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре санга сугылмауга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешендә каралганча, җиңел такси «Россия Федерациясендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләрнең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 29 декабрендәге 580-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән таләпләр нигезендә бизәлергә: җиңел такси кузовының төсләре ак яки сары төсләр гаммасына туры килергә тиеш.

Гражданка Д.Г. Йосыпова, мөрәҗәгатен нигезләп, 2025 елның 29 апрелендә Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына үзенең милкендәге транспорт чарасы турында мәгълүматны җиңел таксиларның төбәк реестрына кертү турында запрос җибәрүен күрсәткән. Мөрәҗәгать итүче, Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатыннан тиешле лицензия алу өчен, эзлекле гамәлләр кылган.

Әмма мөрәҗәгать авторына әлеге хезмәтне күрсәтүдән баш тартканнар. Баш тартуның сәбәбе – зәңгәр төстәге автомобиленең 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән критерийларга туры килмәве.

Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, төбәк законының күрсәтелгән нигезләмәсе Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен боза, Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 статьясындагы икенче өлешенә, шулай ук 50 статьясындагы беренче һәм өченче өлешләренә каршы килә, хезмәт өлкәсендә дискриминацион шартлар тудыра һәм билгеле бер төсләр гаммасындагы транспорт чараларына ия булган гражданнарның җиңел машинада пассажирлар йөртү өлкәсендә хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруга хокукларын нигезсез чикли. Ул кертелгән чикләүләрнең объектив нигезләнешкә ия булмавын ассызыклаган, чөнки алар

куркынычсызлыкны тәэмин итүгә бәйле түгел, шул рәвешле хокук субъектлары тигезсез хәлгә куела.

Гражданка Д.Г. Йосыпова Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасында җиңел таксиларга билгеле бер төсләр гаммасын кертүне гомуми транспорт ташкынында халыкка аларны тануны җиңеләйтү зарурилыгына бәйле рәвештә аңлатуы белән килешмәвен белдергән. Ул ак һәм сары төстәге автомобильләрнең җиңел машинада пассажирлар йөртү өлкәсендә кулланыла торган транспорт чаралары өчен уникаль булып тормавын басым ясап әйткән. Аның фикеренчә, ак һәм сары төстәге күп кенә автомобильләр пассажирлар йөртү өлкәсендә эшләми. Машиналарның тыгыз ташкынында үзләренә хас билгеләре буенча: түбәсендәге яктырткычы һәм кузовындагы “шашкалары” буенча таксины җиңел генә танырга мөмкин. Транспорт чарасының төсе берничек тә тану критерие буларак хезмәт итми, такси йөртүченең эшлекле сыйфатларына, сервис дәрәҗәсенә, автомобильнең техник торышына һ. б. йогынты ясамый.

Мөрәҗәгать итүче билгеләп үткәнчә, норматив-хокукый актның дәгъва белдерелгән нигезләмәсе шундый вазгыятьне күз алдына китерә: машинасы “дөрес” төстә булган, әмма начар гадәтләрдән интеккән, җитәрлек дәрәҗәдә рус һәм (яисә) татар телләрен белмәгән, юл хәрәкәте кагыйдәләрен һаман саен бозып торган, техник торышы начар булган транспорт чарасыннан файдаланучы затка таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыруга өстенлекле хокук бирелергә мөмкин. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасының Төп законында билгеләнгән кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре тигезлегенең конституциячел принцибына турыдан-туры каршы килә, ә ул мөлкәт буенча, социаль статус буенча, һөнәри сыйфатларга һәм хокукый нормаларны үтәүгә бәйле булмаган башка хәлләр буенча дискриминациянең юклыгын гарантияли.

Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, гамәлгә кертелгән норматив-хокукый җайга салу республиканың меңләгән үзмәшгуль машина йөртүчесенә, акча эшләүнең альтернатив, еш кына легаль булмаган ысулларын эзләү зарурилыгы алдында калдырып, законлы керем чыганагын югалту куркынычын тудыра. Бу аларның хезмәт стажы өзелүгә һәм, шуның нәтиҗәсе буларак, бюджетка салым керемнәрен киметүгә китерәчәк. Ә мондый хәл бары тик транспорт чаралары төсенә кагылышлы формаль таләп аркасында гына килеп чыгачак. Шул рәвешле башбаштаклыкка тартым критерийларга нигезләнгән чикләү транспорт хезмәтләре бәясенең артуына, халык өчен таксида йөрү мөмкинлегенең кимүенә китерәчәк һәм, ахыр чиктә, халыкның түләү сәләтенә тискәре йогынты ясаячак.

Гражданка Д.Г.Йосыпова, югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, Татарстан Республикасы Конституция советыннан «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 2023 елның 21 июлендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешен Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 статьясындагы икенче өлешенә, 50 статьясындагы беренче һәм өченче өлешләренә туры килми дип тануны сорый,

ә алар нигезендә, дәүләт, чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, нинди расадан һәм милләттән булуына, җенесенә, белеменә, теленә, сәяси

карашларына, дингә мөнәсәбәтенә, фикерләренә, шөгыльләренең төренә һәм характерына, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә, кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген гарантияли; хезмәтнең ирекле булуын; һәркемнең үз ихтыяры белән хезмәткә сәләтен эшкә җигә алуын, эшчәнлек төрен һәм һөнәр сайлауга хокуклы булуын; һәркемнең куркынычсызлык һәм гигиена таләпләренә җавап бирердәй шартларда хезмәткә хокуклы булуын, ниндидер кимсетелүләрсез һәм федераль законда билгеләнгән минималь хезмәт хакы күләменнән түбән булмаган хезмәт хакы алуын, шулай ук эшсезлектән яклау хокукына ия булуын гарантияли.

Карауга чыгарылган мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы Конституция советына Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Дәүләт автоинспекциясе идарәсе, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил вәкилләре үзләренең бәяләмәләрен җибәрде.

Бәяләмәләрдә дәгъва белдерелгән норманың Татарстан Республикасының Төп законына туры килүе билгеләнә, бу федераль закон чыгаручы тарафыннан Россия Федерациясе субъектларына җиңел таксиның төсенә карата таләпләрне билгеләү хокукы бирүгә бәйле. Төбәкнең закон чыгаручысы, үзенең норма чыгару компетенциясе кысаларында, 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешендә җиңел такси кузовы төсләренең бары тик ак яисә сары төстә генә булырга тиешлеген билгеләгән. Татарстан Республикасы закон чыгаручысы, җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затларга күбрәк мөмкинлекләр бирергә омтылып, кузовка бердәм төсләр билгеләү белән генә чикләнмичә, охшаш төсләр гаммасын да керткән. Бәяләмәләрдә билгеләп үтелгәнчә, әлеге карар пассажирлар йөртү өлкәсендә эшләүче эшмәкәрләр һәм оешмалар өчен төс сайлау мөмкинлекләрен киңәйтергә тиеш.

Россиянең кайбер төбәкләрендә җиңел таксиларның төсләр бизәлешенә карата шундый ук таләпләр каралган. Төсләр гаммасына таләпләр хезмәткә хокукны гамәлгә ашыру өчен дә, эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен дә җиңә алмаслык киртә булып тормый. Җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашырырга ниятләгән зат билгеләнгән төсләр гаммасына туры килә торган транспорт чарасын сатып алу яисә таләп ителгән төстәге автомобильне арендалау хезмәтеннән файдалану мөмкинлеген саклый. Таксиларның тышкы “кыяфәтен” бердәйләштерү юнәлдерелгән кайбер өстәмә шартлар куелса да, эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнү мөмкинлеге саклана.

«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» 2023 елның 13 июнендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 2 өлеше нигезендә бәяләмә чыгарганда, Конституция советы карауга чыгарылган норматив-хокукый актның туры мәгънәсен бәяли. Татарстан Республикасы Конституция советы норматив-хокукый актны

караганда, шулай ук аңа рәсми аңлатмалар һәм башка аңлатмалар белән бирелгән яисә гамәлдәге хокук куллану практикасы биргән мәгънәне бәяли. Конституция советы мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча гына бәяләмә чыгара, ә норматив-хокукый актны караганда – мөрәҗәгатьтә конституциячеллеге шик астына алынган өлешенә карата гына бәяләмә чыгара. Татарстан Республикасы Конституция советы бәяләмә чыгарганда мөрәҗәгатьтә бәян ителгән нигезләргә һәм дәлилләргә бәйле була алмый.

Шул рәвешле, Татарстан Республикасы Конституция Советының карап тикшерү предметы булып «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 2023 елның 21 июлендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлеше – җиңел такси кузовы төсләренең бары тик ак яисә сары гаммага туры килүен билгеләүгә кагылышлы өлеше тора.

Карауга чыгарылган закон нигезләмәсенә тиешле конституциячел-хокукый бәя Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясе буенча җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга сала торган федераль законнарның норматив-хокукый актлары белән системалы бәйләнештә бирелергә мөмкин.

2. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешенең «б» һәм «к» пунктлары) нигезендә, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау, законлылыкны һәм хокук тәртибен, иҗтимагый иминлекне тәэмин итү, шулай ук административ законнар Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагындагы өлкәгә кертелгән. Әлеге компетенция кысаларында күрсәтелгән өлкәләрдә гомуми принципларны билгеләүче федераль законнар чыгарыла.

Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы (2 өлеш) нигезендә, Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив-хокукый актлары чыгарыла.

Уртак карамактагы эшләр өлкәсендә Россия Федерациясе субъекты закон чыгаручысы Федераль законда билгеләнгән норманы үстерергә һәм тәанеләштерергә хокуклы, шулай ук уртак карамактагы эшләргә караган мәсьәләләр Федераль законда җайга салынмаган очракларда, алар буенча мөстәкыйль рәвештә хокукый җайга салуны гамәлгә ашырырга хокуклы (Россия Федерациясе Конституция судының 2003 елның 15 декабрендәге 19-П номерлы карары).

Шулай итеп, Россия Федерациясе субъекты, әлеге хокук мөнәсәбәтләрендә федераль законнарда, дәүләт хакимияте федераль органнарының башка хокукый актларында каралган һәм рөхсәт ителгән дәрәҗәдә катнашып, карауга чыгарылган шушы очракта иҗтимагый иминлекне тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләрне җайга салуда (төбәк үзенчәлекләрен исәпкә алып) үзенә йөкләнгән бурычларны нәтиҗәле хәл итү ысулларын күздә тотуга хокуклы. Мондый система Россия Федерациясенең бөтен территориясендә килеп чыгучы сынауларны нәтиҗәле хәл кылу һәм гражданнар, җәмгыять мәнфәгатьләрен яклау-саклауны тәэмин итү

мөмкинлеге бирә торган комплекслы һәм күп баскычлы хокукый җайга салуны тәэмин итә.

Региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү, җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру, җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташу өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомум принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 1 өлешенең 21, 23 һәм 24 пунктлары нигезендә, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә. кертелә. Күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан мөстәкыйль рәвештә, субъект бюджеты акчалары хисабына, Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы эшләре буенча гамәлгә ашырыла, федераль бюджеттан субвенцияләр бирү очракларыннан тыш.

Россия Федерациясе территориясендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүнең хокукый нигезләре «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнә, законның бурычлары юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү, алардан килгән зыянның авырлыгын киметү юлы белән гражданнарның гомерен, сәламәтлеген һәм мөлкәтен саклау, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрен яклаудан гыйбарәт (1 статья).

Күрсәтелгән Федераль законның 4 статьясында юл хәрәкәте иминлеге турында Россия Федерациясе законнарының әлеге федераль законнан һәм башка федераль законнардан, шулар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актларыннан, Россия Федерациясе субъектларының законнарыннан һәм башка норматив-хокукый актларыннан, муниципаль хокукый актлардан торуы билгеләнгән.

Җиңел таксида пассажирлар һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендәге хокукый мөнәсәбәтләр, шулай ук Россия Федерациясе территориясендә күрсәтелгән өлкәдә дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештырганда барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр «Россия Федерациясендә җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләрнең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 29 декабрендәге 580-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына (алга таба – 580-ФЗ номерлы Федераль закон).

Күрсәтелгән федераль законның кайбер нигезләмәләре Россиянең бөтен территориясендә үтәлергә тиеш, шул ук вакытта федераль хакимият органнары тарафыннан Россия Федерациясе субъектларына аерым вәкаләтләр тапшырыла, бу исә карауга чыгарылган өлкәдә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашырганда төбәк үзенчәлекләрен һәм ихтыяҗларын исәпкә алырга мөмкинлек бирә.

580-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеге,

юридик затка, индивидуаль эшкуарга яисә физик затка бирелә торган һәм җиңел таксида йөртүчеләрнең региональ реестрындагы язу белән раслана торган рөхсәт нигезендә, мәгълүматлары җиңел таксиларның региональ реестрына кертелгән транспорт чараларыннан файдаланып, рөхсәтнең гамәлдә булуы туктатып торылмаган яки гамәлдән чыгарылмаган шартларда, хәл ителә.

Җиңел таксиның тышкы бизәлешенә таләпләрне билгеләгән 580-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә, Россия Федерациясе субъектларына үз территорияләрендә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен кулланыла торган җиңел таксилар кузовының төсләрен закон нигезендә билгеләү хокукы бирелгән.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан, 580-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән Россия Федерациясе субъектының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатында, «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 2023 елның 21 июлендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән, ул җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру өлкәсендә һәм Татарстан Республикасы территориясендә күрсәтелгән өлкәдә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруда аерым мәсьәләләрне җайга сала (71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы).

71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешендә җиңел такси кузовы төсләренең ак яисә сары төсләр гаммасына туры килергә тиешлеге билгеләнгән.

Шул рәвешле Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, җиңел такси кузовының төсләренә таләпләр куеп, Россия Федерациясе Конституциясендә күздә тотылганча, халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өлкәсендә Россия Федерациясе һәм аның субъектлары карамагындагы уртак эшләр чикләрен билгеләүдән чыгып эш иткән. Әлеге карар Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясындагы 2 пунктында билгеләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында кабул ителгән, аның нигезендә Татарстан Республикасы карамагындагы мәсьәләләр буенча һәм Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча законнар нигезендә җайга салу эше Татарстан Республикасы вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына керә.

3. Россия Федерациясе Конституциясенең 8 статьясында (1 өлеше) икътисадый эшчәнлек иреге конституциячел корылыш нигезләренең берсе буларак игълан ителгән. Икътисадый ирек принцибы нигезендә эшкуарлык эшчәнлеге һәм закон белән тыелмаган башка икътисадый эшчәнлек өчен үз сәләтеңнән һәм мөлкәтеңнән ирекле файдалануга Конституциядә гарантияләнә торган хокукның эчтәлеген тәшкил итүче хокуклар ята, аны гамәлгә ашырганда, гражданнар әлеге эшчәнлек өлкәсен сайлый һәм аны индивидуаль рәвештә, йә башка затлар белән бергә, милеккә хокукның һәм дәүләт тарафыннан намуслы көндәшлеккә ярдәм итүнең конституциячел гарантияләреннән файдаланып, хәл итә ала (Россия Федерациясе Конституциясенең 8, 34 һәм 35статьялары).

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Конституциясенең 8, 17 (3 өлеше), 34 (2 өлеше), 35 (1 һәм 2 өлешләре) һәм 55 (3 өлеше) статьялары мәгънәсе

буенча эшкуарлык эшчәнлеге һәм закон белән тыелмаган башка икътисадый эшчәнлек өлкәсендәге хокуклар һәм ирекләр башка затларның хокукларын һәм ирекләрен бозып гамәлгә ашырылырга һәм конституцион нигездә якла용ла торган кыйммәтләрне куркыныч астына куярга тиеш түгел.

Россия Федерациясе Конституция судының 2008 елның 18 июлендәге 10-П номерлы карарында күрсәтеп үтелгәнчә, аерым алганда, базардагы үзара хезмәттәшлектә катнашучыларның хокуклары һәм бурычлары балансын тәэмин итү зарурилыгында чагыла торган гаделлек принцибы нигезендә хуҗалык итүче субъектлар таный торган ирек һәм ул гарантияли торган яклау хуҗалык итүче субъектларның хуҗалык эшләре үзләренә кагылучыларның хокукларына һәм ирекләренә карата җаваплы мөнәсәбәт таләбе белән тигезләштерелергә тиеш. Бу Россия Федерациясе Конституциясенең гражданның хокукларын һәм бурычларын тиешле балансга китерүне тәэмин итү зарурилыгы турындагы 75.1 статьясы нигезләмәсенә дә туры килә.

Россия Федерациясе Конституция Суды 2010 елның 13 июлендәге 16-П номерлы карарында билгеләп үткәнчә, эшкуарлык эшчәнлеге үзенең табигате буенча табыш алуга юнәлтелгән һәм уңышсыз килеп чыгу ихтимады да булганга, димәк, күп санлы затларның, беренче чиратта эшкуарлык эшчәнлеге субъекты клиентларының һәм контрагентларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга китерергә мөмкин булганга күрә, федераль закон чыгаручы Россия Федерациясе Конституциясенең 17 статьясына (3 өлеше), 19 (1 һәм 2 өлешләре), 34,35 һәм 55 (3 өлеше) статьяларына таянып, аны гамәлгә ашыру шартларын, хосусый икътисадый инициативаны башка затлар һәм тулаем җәмгыять мәнфәгатьләре белән килештерү максатларында, тиешле күләмдә һәм сыйфатта гавами әһәмиятле хезмәтләр күрсәтү ихтыяҗларын да кертеп, билгеләргә һәм тиешле контрольлекне, шул исәптән тирә-юньдәгеләргә югары дәрәҗәдәге куркыныч белән бәйле булган эшчәнлекнең бигеле бер төрләре белән шөгыльләнү өчен кирәкле булга нмөлкәттән файдалануга контрольлекне күздә тотарга тиеш.

Күрсәтелгән карардан күренгәнчә, югары куркыныч чыганагы булган транспорт чараларыннан (шул исәптән таксилардан) файдалануга бәйле буларак, халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеген хәл кылу хокукын гамәлгә ашыру пассажирларның һәм юл хәрәкәтендә катнашучы башкаларның иминлеген тәэмин итүнең махсус чараларын күрү һәм нигезле, шул исәптән чикләү характерындагы, ягъни Россия Федерациясе Конституциясенең 55 статьясы (3 өлеше) нигезендә билгеләнгән таләпләр кертү зарурлыгына китерә.

Россия Федерациясе субъектларының җиңел такси кузовының төсләр гаммасын билгеләү хокукын законнар нигзенедә билгеләү җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга таләпләрне регламентлаштыра торган 580-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктына нигезләнгән.

Татарстан Республикасы закон чыгаручысы, үзенең законнар иҗат итү компетенциясен гамәлгә ашырып һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә һәм такси тармагын транспорт агымында җиңел танып белү өчен автомобильләрнең төсләр бертөрлелегенә һәм идентификация уникальлегенә китерергә омтылып, 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6

статьясындагы 1 өлешендә җиңел такси кузовы төсләренең ак яки сары төсләр гаммасына.туры килергә тиешлеге турында норманы күздә тоткан.

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция судының 2010 елның 13 июлендәге 16-П номерлы карарында бәян ителгән һәм югарыда китереп үтелгән позициясенә туры килә, анда халыкка автомобиль транспорты белән хезмәт күрсәткәндә юл хәрәкәте иминлеге, аерым алганда, пассажирларны таксиларда йөртү иминлеге һәм эшкуарлык эшчәнлеге иреге кебек кыйммәтләр балансын саклау зарурилыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе субъектының закон чыгаручысының, федераль законнарны бозмыйча, Россия Федерациясе субъектында индивидуаль файдаланудагы таксиларда пассажирлар йөртү өлкәсендә мондый пассажирлар йөртүнең иминлеген тәэмин итәрлек итеп эшкуарлык эшчәнлегенең хокукый режимын билгеләргә хокуклы булуы күрсәтелгән.

Такси – коммерция хезмәте генә түгел ,ә пассажирның иминлеге һәм тынычлыгы гарантиясе дә. Шәһәр маршрут автобуслары үзләренең таныла торган төсләр гаммасы һәм танылa торган тышкы билгеләре белән транспорт агымында аерылып торган кебек, такси да җиңел идентификацияләнергә тиеш. Гражданнар җәмәгать транспортын корпоратив яки хосусый транспорттан, аның визуаль характеристикаларыннан чыгып, хатасыз аера.

Карауга чыгарылган өлкәдә региональ җайга салу берничә мөһим максатны күздә тота: пассажирлар йөртүнең танылуын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү (бердәм төсләр гаммасы һәм танып белү билгеләре, кулланучыларның хезмәт күрсәтүгә ышанычын ныгытып, легаль таксины тиз генә танып алуга ярдәм итә), җәмәгать транспорты оешмаларының легаль булмаган эшчәнлегенә каршы тору (билгеләнгән региональ стандартларга җавап бирми торган транспорт чараларын ачыклауны җиңеләйтү), уникаль төбәк брендын формалаштыруга ярдәм итү (расланган төс төбәкнең визуаль йөзенең аерылгысыз өлеше булырга мөмкин), һәм, ниһаять, пассажирлар йөртү базарында катнашучыларның барысы өчен төгәл кагыйдәләр һәм унификацияләнгән стандартлар кертү юлы белән пассажирлар йөртү базарын тәртипкә китерү.

Дәүләт тарафыннан җайга салына торган такси хезмәтләреннән аермалы буларак, эшчәнлегенә лицензиясе булмаган таксистларга утырып йөрү шәхси килешү шартларында, бәхәсле хәлләр килеп чыккан очракта, хокукый яклау гарантияләреннән башка гына башкарыла. Югарыда күрсәтелгәнчә, төс белән аерылып тору транспорт чарасын хатасыз идентификацияләү өчен кирәк, бу пассажир куркынычсызлыгының беренчел факторы булып тора. Ул авторизацияләнмәгән һәм куркыныч белән янау ихтималы булган транспорт чараларына очраклы утыруларны булдырмаска мөмкинлек бирә, шулай ук күрсәтелә торган хезмәтнең ышанычлылыгына һәм легальлегенә ышанычны тәэмин итеп, алдаудан һәм мошенниклыктан саклый.

Такси автомобильләре өчен унификацияләнгән төсләр гаммасын кертү ышанычлы һәм лицензияле таксистны сайлауны җиңеләйтә, бу исә, ахыр килеп, тармакка ышанычны ныгытуга ярдәм итә. Әлеге чара күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын контрольдә тотуның нәтиҗәле ысулы булып тора, чөнки кулланучыларга легаль таксиларны легаль булмаганнарыннан тизрәк һәм җиңелрәк аерырга мөмкинлек бирә. Димәк, бердәм төсләр гаммасын кертү

кулланучылар хокукларын яклауга һәм пассажирлар йөртү өлкәсендә сервисның гомуми дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелә.

Җиңел такси кузовының ак яисә сары төсләр гаммасы турындагы таләп элек гамәлдә булган «Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу турында» 2011 елның 10 октябрендәге 77-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законында да булган, аның нигезендә «Россия Федерациясенең аерым законнар актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 21 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 16 өлешенең 1 пунктының «в» пунктчасында (статья үз көчен югалткан) билгеләнгән Россия Федерациясе субъектларының мондый таләпне билгеләү хокукы гамәлгә ашырылган.

Бу очракта республика закон чыгаручысы хокукый яктан билгеле булу принцибын үтәгән, аның мөһим аспекты булып хокук мөнәсәбәтләре субъектларының хокукый статусының тотрыклылыгын таләп итү тора. Тиешле хокук мөнәсәбәтләрендә катнашучыларга йөкләмәләр йөкли торган яңа хокукый җайга салу гражданнарның законга һәм дәүләт гамәлләренә ышанычын саклау принцибын үтәү нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш. Бу хокукый җайга салуның тиешле тотрыклылыгын саклауны һәм гамәлдәге нормалар системасында башбаштаклыкка нигезләнгән үзгәрешләргә юл куймауны күздә тота.

Мондый алым социаль бердәмлекне ныгытуга ярдәм итеп кенә калмый, ә җәмгыятьнең тотрыклы үсешен дә тәэмин итә, бу очракта һәр шәхес үз хокукларының якланганлыгын һәм законнарның ышанычлы булуын тоя һәм аларга ышана да.

Моннан тыш, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 21 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының үз көчен югалтуы танылганчы, Россия Федерациясе Конституция судына шикаять бирелгән, анда гражданин күрсәтелгән статьяның 16 өлешендәге 1 пункты нигезләмәсен һәм җиңел такси кузовына карата шундый ук төсләрне билгеләгән «Краснодар краенда халыкка җиңел такси белән транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру турында» 2007 елның 27 мартындагы 1217-КЗ номерлы Краснодар крае Законының 8 статьясындагы 1 өлешендәге «а» пунктының Россия Федерациясе Конституциясенең 8 статьясына (1 өлеше), 19 статьясына (2 өлеше) һәм 34 статьясына (1 өлеше) туры килмәвен тануны сораган.

Моңа кадәр үзенә пассажирлар йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга рөхсәт бирүдән баш тартылган мөрәҗәгать итүче фикеренчә, билгеләнгән Закон нигезләмәләре артыкка киткән, алар конкуренцияне чикләүгә китергән һәм аны хезмәт хокукыннан мәхрүм иткән.

Россия Федерациясе Конституция судының 2018 елның 27 мартындагы 713-О номерлы билгеләмәсе белән, федераль законның һәм Россия Федерациясе субъекты законының дәгъва белдерелә торган нигезләмәләренең җиңел таксида пассажирлар йөртү өлкәсендә барлыкка килә торган хокукый мөнәсәбәтләрнең барлык якларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә юнәлдерелгән булуы һәм шикаятьтә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын бозу буларак карала алмавы сәбәпле, шикаятьне карап тикшерүгә кабул итеп алудан баш тартылган.

Россия Федерациясенең Югары суд органы җиңел такси кузовының төсләр гаммасын билгели торган Россия Федерациясе субъекты законының Россия Федерациясе Конституциясенә туры килү мәсьәләсендә билгесезлек күрмәгән.

Җиңел таксиның төсләр гаммасы буенча дәгъва белдерелә торган чикләү, норматив хокукый акт формасына, аны кабул итү, бастырып чыгару һәм гамәлгә кертү тәртибенә карата таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан үзенең вәкаләтләре чикләрендә билгеләнгән, гамәлдәге законнарның җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә иминлекне тәэмин итүгә юнәлдерелгән югарыда күрсәтелгән нигезләмәләренә туры килә.

Татарстан Республикасы законнар чыгару хакимияте органы, юл хәрәкәте иминлеге турындагы федераль законнарның гомуми нигезләмәләрен төгәлләштереп, республиканың уникаль төбәк үзенчәлекләрен һәм финанс-икътисадый мөмкинлекләрен исәпкә алган. Карауга чыгарылган норматив-хокукый актны кабул итү вакытына килеп туган хәлне исәпкә алып, кертелә торган чаралар нигезле нигезләнешкә ия һәм конституциячел әһәмиятле кыйммәтләрне саклауның объектив зарурлыгы белән билгеләнгән, нигезләнгән һәм аңа туры килә, җәмгыятьнең һәм шәхеснең законлы мәнфәгатьләре балансын саклау бурычына каршы килми.

Төбәк закон чыгаручысы дәгъва белдерелә торган нигезләмәне кабул итү белән конкуренцияне чикләмәгән, ә федераль закон нигезендә үзенә бирелгән җиңел транспортта пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен өстәмә таләп билгеләү вәкаләтен гамәлгә ашырган. Бәхәсле хокукый мөнәсәбәтләрдә катнашучылар җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыру эшчәнлегенә керүнең дискриминацион шартларына урын калдырмаган шул бер үк хәлгә куелган. «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташуны оештыру турында» 2023 елның 21 июлендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешендә бәян ителгән нигезләмә җиңел таксиларда пассажирлар йөртү һәм багаж ташу эшчәнлеген гамәлгә ашыруга карата бердәм таләпләр билгеләнгән, алар, бернинди искәрмәләрсез.Татарстан Республикасы территориясендә эш итүче барлык пассажир йөртүчеләргә дә кагыла.

Татарстан Республикасы Конституция советы, бәян ителгәннәрне игътибарга алып, «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 2023 елның 21 июлендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән хокукый җайга салу, җиңел такси кузовының төсләр гаммасының бары тик ак яисә сары төсләргә туры килүен күрсәтеп җайга сала торган өлешендә Дәүләт Советы тарафыннан үзенең дискрецион вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән, дигән нәтиҗәгә килде. Татарстан Республикасы Әлеге карар хосусый икътисадый инициатива һәм башка затлар, шулай ук тулаем җәмгыять мәнфәгатьләре арасында балансны саклау принципларына нигезләнә һәм Татарстан Республикасы территориясендә тиешле хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салуда хокукый билгеләнешне тәэмин итәргә омтыла. Шул рәвешле, карауга чыгарылган хокукый җайга салу үзеннән-үзе

гражданнарның конституциячел хокукларын, шулай ук мөрәҗәгать итүченең хокукын бозу буларак бәяләнә алмый һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 статьясындагы икенче өлешенә һәм 50 статьясындагы беренче һәм өченче өлешләренә туры килә.

4. Татарстан Республикасы Конституция советы мөрәҗәгать итүченең такси кузовының төсләр гаммасына таләпләр кертелүгә бәйле рәвештә башка төстәге автомобильләр йөртүчеләргә ак яисә сары төстәге транспорт чарасы сатып алуга, аны буяуга һ. б. бәйле өстәмә финанс чыгымы йөкләнүен күрсәтүче дәлилләрен игътибарга алды.

Татарстан Республикасында такси базарының динамикалы үсеше шактый ук дәрәҗәдә кече һәм урта бизнес предприятиеләре тарафыннан тәэмин ителә.

Автомобильне «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 2023 елның 21 июлендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән критерийларга туры китерү зарурилыгы җиңел таксида эшләргә ниятләүчеләрнең бер өлешенең җиңел таксида пассажирлар йөртү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашырудан баш тартуына китерергә мөмкин.

Тиешле төсләр гаммасындагы яңа транспорт чарасын сатып алу белән бәйле финанс чыгымнары автомобиль хуҗаларын, аерым алганда, шәхси автотранспортны коммерция максатларында кулланучы үзмәшгуль затларны кыен хәлгә куя. Транспорт чаралары белән тәэмин итүнең кимүенә һәм аларны ремонтлау мөмкинлекләренең чикләнүенә китерә торган гамәлдәге икътисадый санкцияләр шартларында такси автомобильләрен яңадан буяуга өстәмә чыгымнар машина йөртүчеләрнең тиешле эшчәнлек алып бару теләгенә тискәре йогынты ясарга мөмкин. Әлеге хәл шулай ук аларның шәхси эшмәкәрләр, кече яки урта эшмәкәрлек субъектлары буларак эшчәнлеген легальләштерү юлында өстәмә киртә булып торырга мөмкин.

Шуның белән бергә, Россия Федерациясе Конституциясенең 8 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән икътисадый эшчәнлек иреге принцибы эшкуарлык эшчәнлеге субъектына әлеге эшчәнлекне мөстәкыйль рәвештә, үз мөмкинлекләреннән чыгып башкару хокукы бирә. Бу хокук кабул ителә торган гамәлләрнең нәтиҗәлелеген һәм максатка ярашлылыгын бәйсез һәм кешенең үзе тарафыннан гына бәяләү мөмкинлеген, шулай ук базар конъюнктурасыннан һәм үзенең исәп-хисапларыннан чыгып фаразланыла торган керемнәрне һәм чыгымнарны мөстәкыйль билгеләүне үз эченә ала.

Татарстан Республикасында җиңел такси йөртүчеләрнең югарыда телгә алып үтелгән эшчәнлеккә бәйле рәвештә тоткан чыгымнары уңышсыз да килеп чыгу куркынычы булган һәм шәхси эшкуарлык инициативасын гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән мөстәкыйль эшкуарлык эшчәнлеге барышында барлыкка килә торган чыгымнар булып тора. Башкача әйткәндә, әлеге чыгымнарны тоту коммерция эшчәнлеген алып баруның аерылгысыз өлеше булып тора.

5.Хокукның социаль әһәмияте аның иҗтимагый алгарышка катализатор булып хезмәт итү мөмкинлеге белән ачыла, бөтен социумга да, һәр законнарны үтәүче гражданинга да хокукый нормаларны билгеле һәм яклый торган

социаль әһәмиятле максатларны гамәлгә ашыру мөмкинлеген тәэмин итә. Хокукый җайга салуның перспективалы тенденцияләреннән берсе булып хокук һәм социаль җайга салуның башка формалары арасында баланс эзләү тора.

Нәкъ менә икътисадый үсешкә ихтыяҗлар, шулай ук хокукый нормаларны кабул итү, үзгәртү яки юкка чыгару юлы белән иҗтимагый мөнәсәбәтләрдә барлыкка килгән проблемаларны хәл итүгә социаль запрос тиешле хокукый карарларын кабул итүне һәм аларның эчтәлеген билгели, аларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелегенә турыдан-туры йогынты ясый. Моннан күренгәнчә, реаль ихтыяҗлардан аерылган һәм күзгә күренеп торган социаль запрос булмаганда кабул ителгән хокукый карарлар әлеге карарларның нәтиҗәлелеген киметүгә китереп, яхшы ниятне формальлеккә әйләндерә.

Социаль яшәеш шартлары һәм икътисадның ихтыяҗлары хокукый җайга салуның зарурилыгын һәм үзенчәлекләрен тудыра, хокукый күрсәтмәләрне алга таба куллану өчен нигез булып тора, ул бары тик социаль мәнфәгатьләргә туры килгән очракта гына нәтиҗәле булачак. Бу факторлар, җитәрлек дәрәҗәдә матди ресурслар һәм алга киткән икътисадка ия булганда, хокукый карарларын тормышка ашыруның объектив мөмкинлеген билгели.

Әлеге мөрәҗәгатьне карау предметы булган хокукый җайга салу нәтиҗәләре буенча эшләнә торган механизмнарның социаль-икътисадый мөнәсәбәтләргә тискәре йогынтысы ачыкланса, иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең тиешле өлкәсендә тискәре нәтиҗәләрне киметүгә яисә җайга салуның альтернатив (нәтиҗәлерәк) вариантларын кертүгә юнәлдерелгән законнардагы үзгәрешләр таләп ителергә мөмкин.

Карауга чыгарылган закон нормасының Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 статьясындагы икенче өлешенә, 50 статьясындагы беренче һәм өченче өлешләренә туры килүен тану Татарстан Республикасы Дәүләт Советына үзенең дискрецион вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында, социаль запросларны һәм югарыда санап үтелгән башка хәлләрне анализлаудан чыгып, җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өлкәсендә норматив-хокукый җайга салуны үзгәртү мөмкинлеген карарга комачауламый.

Татарстан Республикасы Конституция советы, бәян ителгәннәр нигезендә һәм «Татарстан Республикасы Конституция советы турында» 2023 елның 13 июнендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 2 өлешенә, 11 статьясына, Татарстан Республикасы Конституция Советы Регламентының 32-35 статьяларына туры китереп,

НӘТИҖӘ ЧЫГАРДЫ:

1. Нигезләмәләрендә җиңел такси кузовы төсләренең бары тик ак яисә сары төсләр гаммасына туры килүе мәҗбүри буларак күрсәтелгән «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 2023 елның 21 июлендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы 1 өлешен Татарстан Республикасы Конституциясенең

28 статьясындагы икенче өлешенә, 50 статьясындагы беренче һәм өченче өлешләренә туры килә дип танырга,

2. Әлеге Нәтиҗәне «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга шулай ук Татарстан Республикасы Конституция советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Конституция советы рәисе — И.И. Гыйлаҗев

Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзалары — Р.Ф. Гафаров

Э.М. Мостафина